**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзаларының (академикларының) һәм мөхбир-әгъзаларының гомуми санын раслау турында

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе уставы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзаларының (академикларының) һәм мөхбир-әгъзаларының 115 кешедән торган гомуми санын, шул исәптән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең 56 хакыйкый әгъзасын (академигын) һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең 59 мөхбир-әгъзасын расларга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясен төзү турында» 1991 елның 30 сентябрендәге ПУ-138 номерлы Указының 3 пункты беренче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 564